МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.06.2015 г.Казань № 122/2-пр

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2015 елның 12 мартындагы 37/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

“Россельхозбанк” ААҖнең Татарстан төбәк филиалында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында кадрлар үзгәреше булу сәбәпле һәм “Хуҗалык җәмгыятьләренең мөһере булу мәҗбүрилеген бетерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 6 апрелендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 – 2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу конкурсы турында” 2015 елның 12 мартындагы 37/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составыннан В.Я. Муллинаны һәм Р.Р. Кашапованы чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына Григорьев Алексей Евгеньевичны - “Россельхозбанк” ААҖнең Татарстан төбәк филиалы директоры урынбасарын һәм Парфенова Лариса Александровнаны – “Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм үстерү программаларын гамәлгә ашыру үзәге” дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе урынбасарын кертергә.

1.2. Боерыкка 2 нче кушымтада:

“Гаризаларны кабул итү һәм теркәү” 4 бүлегенең 4.2 пунктындагы 3 абзацта “КФХ мөһере белән таныклана торган” сүзләреннән соң “(мөһер булган очракта)” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөклим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов